«КИЛЕШЕНГӘН»
МБМББУ 4нче «Шаянкай»
балалар бакчасы мөдире
_______ Л.А.Нагимова

4 нче «Шаянкай» балалар бакчасы
мөдире приказы белән гамәлгә кертелгән
«_25_» ____08_____2024 ел. №_243_

Педагогик совет утырышында
расланган
«_29_» ____08_____2024 ел.
Проктокол № _1_

# 3 нче икенче кечкенәләр төркеменең
# 2024-2025 уку елына эш программасы
# (3 яшьтән 4 яшькә кадәр)

төркем тәрбиячеләре:
Смирнова Айгөл Фәнил кызы

**Яр Чаллы**

# Эчтәлек

**Кереш**.............................................................................................................................3
**Максатчан бүлек**..............................................................................................................3
1.1 Программаны язуда һәм тормышка ашыруда мөһим булган характеристикалар. (программаның максаты һәм бурычлары,төп принциплары, 3-4 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре,төркемнең социаль паспорты,төркемнең приоритетлы юнәлеше)......................................................................................................................3
1.2 3-4 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре.....................................................5
1.3 Программаны үзләштерүнең максатчан юнәлеше...........................................................7
**2 Эчтәлек бүлеге**..................................................................................................................8
2.1 Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге.....................................................................................8
2.2 Белем бирү эшчәнлегенең комплекслы-тематик планы...............................................17
2.3 Гаилә белән үзара бәйләнеш.............................................................................................20
2.4 Социаль дөнья белән таныштыру......................................................................................22
**3 Оештыру бүлеге**...............................................................................................................23
3.1. Материаль-техник кулланма.............................................................................................23
3.2. Методик кулланма...............................................................................................................23
3.3. Үстерешле-предметлы тирәлек..........................................................................................24
3.4. Көндәлек режим..................................................................................................................25
3.5. Турыдан-туры белем бирү эшчәнлегенең расписаниесе..............................................26
3.6. Сәламәтлекне саклау чаралары........................................................................................26
3.7 Традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар...................................................................28
Кулланылган әдәбият исемлеге.............................................................................................29
Эш программасына кыскача призентация............................................................................30
Кушымта....................................................................................................................................31

## Кереш

4нче санлы “Шаянкай” балалар бакчасы  3 нче икенче кечкенәләр  төркемнең эш программасы балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып,белем бирү эшчәнлеген ике төп юнәлештә алып бара: өлкәннәрнең һәм балаларның бердәм эшчәнлеге һәм балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге.

**Программаны тормышка ашыруның төп юнәлеше** – 3-4 яшьлек балаларның танып белү, сөйләм, социаль-коммуникатив, сәнгати-нәфасәти, физик үсешенә шартлар тудыру. Программа балага гуманлы-шәхси позициясендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләре, компетенциясе, сәләте формалашуга юнәлгән. Программада уен эшчәнлеге аерым урын алып тора, баланың туганнан алып мәктәпкәчә чорына кадәр белем һәм тәрбия бирү процессы комплексны бирелгән.

Психологик-педагогик эшнең эчтәлеге биш белем бирү өлкәсе буенча алып барыла

1. “Социаль-коммуникатив үсеш”.
2. “Танып белү үсеше”.
3. “Сөйләм үсеше”.
4. “Сәнгати-эстетик  үсеш”.
5. “Физик үсеш”.

Программаны гамәлгә ашыру белем бирү процессын төзүнең комплекслы тематик принцибына, мәктәпкәчә белем бирүнең бөтенлек һәм интеграция принципларына нигезләнде, балаларның яшьләренә туры килгән эш формаларын һәм эшчәнлек төрләрен исәпкә алып төзелде.

Программа балада һәрьяклы үсешне арттыруга юнәлтелә һәм милли культура, туган якны, туган (татар, рус) телне өйрәнү аша аның баетылуын күздә тота.

11 нче икенче кечкенәләр төркеме “Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү “От рождения до школы»  (Н.Е.Веракса, Т.С.Комаровой, М.А.Васильевой редакциясе .Москва «Мозаика-Синтез», 2010) программасына нигезләнеп эшли.

## 1. Максатчан бүлек.

### 1.1 Программаны язуда  һәм тормышка ашыруда мөһим булган характеристикалар

**Программаның төп максаты** - мәктәпкәчә яшьтәге балаларны эшчәнлекнең төрле төрләре аша яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып һәрьяклап үстерү.

Әлеге максат балалар эшчәнлегенең төрле төрләре: уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив (рәсем ясау, конструктив һ.б.), музыка белән шөгыльләнү, уку процессларында гамәлгә ашырыла.

Программаның максатларына ирешүдә түбәндәгеләр мөһим:

- һәрбер баланың сәламәтлеге, эмоциональ иминлеге һәм үз вакытында төрле яктан үсеше турында кайгырту;
- төркемнәрдә барлык тәрбияләнүчеләргә карата аларны аралашучан, яхшы күңелле, кызыксынучан, инициативалы, мөстәкыйльлеккә һәм иҗатка омтылучан итеп үстерергә ярдәм итәрлек кешелекле һәм яхшы мөнәсәбәт булдыру;
- тәрбия һәм белем бирү процессында барлык төр балалар эшчәнлеген максималь рәвештә куллану;
- тәрбия һәм белем бирү процессын иҗади оештыру;
- балаларның иҗади эшенә хөрмәт белән карау.

**Программаның  бурычлары**

1.Милләтенең, теленең, социаль чыгышының нинди булуына карамастан, һәр  балада аны яратуларына ышаныч, тормыш өчен җайлы шартлар тудыру;

2.Шәхси һәм яшь һәм үзенчәлеге буенча балаларның һәръяклы үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру;

3.Балада социаль-әхлакый, физик, интеллектуаль, эстетик сыйфатлар үстерү;

4.Кеше эшчәнлегенең төп формаларында үзен-үзе ачу һәм иҗат итү сәләтен, ихтыяҗын формалаштыру, дөнья белән берлектә үзен-үзе танып белү, аның белән әңгәмә алып баруга әзерлек;

5.Баланың гомуми шәхси культурасын, шул исәптән сәламәт яшәү рәвешенең кыйммәтен, белем алу эшчәнлегендә алшартны, инициативасын, мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын, актив тормыш позициясен формалаштыру;

6.Һәр баланың сәләтен һәм иҗади потенциалын үстерү;

7.Гуманлык кыйммәтләре һәм идеалы, ирекле кешенең хокуклары нигезендә баланың башка балалар, өлкәннәр һәм әйләнә-тирә белән үзара йогынтысын оештыру; балаларда Ватанга патриотик хис һәм мәхәббәт, рухи-әхлакый һәм социокультура кыйммәтләре нигезендә аның уңышлары өчен горурлану хисе тәрбияләү;

8.Шәхси һәм яшь үзенчәлеге, психо-физиологик үзенчәлекләр буенча социокультура мохите формалаштыру;

9.Гаиләнең һәм җәмгыятьнең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә гаиләнең һәм балалар бакчасының тәрбияви-сәламәтлек ресурсларын берләштерү; гаилә белән үзара партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру, психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү, белем һәм тәрбия бирүдә ата-аналарның компетентлылыгын күтәрү;

10.Балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, максат, бурыч, алымнар, мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомумбелем бирү дәрәҗәсендә күчүчәнлекне булдыру.

**Мәктәпкәчә белем бирүнең төп прициплары**

1.мәктәпкәчә балачакның һәр этабын (сабыйлык, кече яшьтәгеләр; мәктәпкәчә яшьтәгеләр), тулы канунлы итеп оештыру ; балалар иҗат эшчәнлегенең төрле төрләрен оештыру нигезендә үсешне баету (амплификацияләү).

2. Белем бирү эшчәнлеген баланың индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып төзү, шул ук вакытта баланы белем эчтәлеген сайлауда актив катнаштыру.

3. Балалар һәм өлкәннәр арасында хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре булдыру, баланы белем бирү эшчәнлегендә аңа субъект итеп карау.

4. Барлык эшчәнлек төрләрендә балалар инициативасында терәк булу.

5. Оешма һәм гаилә арасында хезмәттәшлек.

6. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны традицион кыйммәтләргә (гореф-гадәтләргә,җәмгыять һәм дәүләт,гаилә традицияләренә)карата приобщение

7. Эшчәнлек барышында балаларның танып белү ихтыяҗларын һәм танып белү гамәлләрен формалаштыру.

8. Мәктәпкәчә белем бирүнең яшь адекватлылыгы (шартларга ярашканлыгы,яшь һәм үстерүнең үзенчәлек методлары,таләпләре).

9. Балалар үсешенең этно-мәдәниятьле ситуациясенең исәп-хисабы.

10. Милли төбәк компоненты (НРК).

**Эш программасы түбәндәге норматив документларга нигезләнеп төзелде:**

1. «Мәгариф турында Россия Федерациясе Законы» Федераль законы, 29.12.2012, № 273-ФЗ.

2. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында» приказы, 17.10.2013, № 1155.

3. Россия Федерациясе Баш санитария табибының «СанПиН 2.4.1.3049-13. «Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының эш режимы төзелешенә, эчтәлегенә һәм оештырылуына карата санитария-эпидемиология таләпләре»н раслау турында» карары, 15.05.2013, № 26.

4. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Төп гомуми белем бирү программалары—мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» приказы, 30.08.2013, № 1014.

5. «4 нче санлы «Шаянкай» катнаш балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең уставы

6. «4 нче санлы «Шаянкай» катнаш балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениясенең төп белем бирү программасы

**Төркемнең социаль паспорты**.

**Балалар турында мәгълүмат.**

| Төрк. бал-р саны | Гаилә составы | | |
|---|---|---|---|
| | тулы | тулы булм | күп балалы |
| 26 бала 16 кыз, 10малай | 25 | 1 | 3 |

**1.2 3-4 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре үзенчәлекләре**

Бала үсешендә мәктәпкәчә яшь чоры күп төрле һәм динамикалы булуы белән аерылып тора. Әлеге чор дәвамында төрле юнәлешләр буенча сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә.

Безнең күз алдында 3-4 ел дәвамында балаларның игътибары, хәтере, фикерләве, күзаллавы, сөйләме көчле үсеш ала. Гади җөмләләр катлаулылары белән алышына һәм кызыклы кечкенә хикәяләргә әверелә. Бу яшьтә баланың дуслары барлыкка килә башлый, ул һәм зурлар белән теләп аралаша, үз тәртибен көйли. Дөнья турында күзаллавы киңәя һәм «нигә?», «ни өчен?» сораулары җавап таләп итә. Мәктәпкәчә яшь чорының башы 3 яшьтәге кискен үзгәреш белән туры килә. Иртә яшьтә үсеш һәм тәрбия дөрес оештырылган булса, баланың 3-4 яшьтә буе 90-100 смга җитә, гәүдә авырлыгы якынча 13-16 кг була. Аның җитезлеге арта, тизрәк йөгерә, яхшырак сикерә, ыргыткан тупны ике кулы белән тотып ала. Әле 2 яшьтә ул бу хәрәкәтләрнең берсен дә эшли белми иде! 3-4 яшьтә балалар физик яктан көчлерәк, мөстәкыйльрәк. Физик тәрбия акыл тәрбиясе белән бәйләнештә алып барыла. Бу яшьтә акыл, эстетик, әхлак, физик үсеш югары темп ала. Мәктәпкәчә яшьтәге бала әйләнә-тирә дөньяны танып белә, күзәткән вакыйгаларны, күренешләрне аңларга тырыша. Дөрес оештырылган педагогик процесс нәтиҗәсендә балалар төрле төшенчәләрне үзләштерәләр, нәтиҗәләр чыгаралар, гомумиләштерәләр. Балаларның кызыксынучанлыгы, яхшы хәтере аңа күп информация тупларга ярдәм итә. Кызыксынучанлык баланы эзләнү эшчәнлегенә, зурларга сораулар белән мөрәҗәгать итәргә стимуллаштыра. Сораулар характеры буенча баланың үсеш дәрәҗәсен билгеләргә була. 3-4 яшьлек баланың аралашуы гаилә белән генә чикләнми. Зурлар бала өчен гаилә әгъзасы гына түгел, ә билгеле иҗтимагый функция үтәүче булып та тора. Баланың шундый ук функция үтәргә теләве аның реаль мөмкинлекләре белән каршылыкка очрый. Әлеге каршылык мәктәпкәчә яшьтә әйдәүче эшчәнлек – уен аша чишелә.

Уенның төп үзенчәлеге , аның шартлы рәвештә булуында. Кече мәктәпкәчә яшьтәге бала уенының төп эчтәлеген уенчыклар һәм предметны алмаштыра торган җиһазлар тәшкил итә. Бу яшьтә балаларның уены озак вакытка сузылмый . Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар уенда бер-ике роль һәм гади сюжетлар белән чикләнәләр. Кагыйдәле уеннар әле формалаша гына башлый.

3-4 яшьлек балаларның эшчәнлеге катлаулана һәм төрләләнә: алар уку һәм хезмәт биремнәрен уеннар аера башлыйлар. Уен һәм шөгыль нәтиҗәсендә психик процесслар (хәтер, фикерләү , игътибар, күзаллау) үсеш ала, балаларның яңа ихтыяҗлары һәм мәнфәгатьләре барлыкка килә.

Информатив, катлаулы һәм күләмле күрсәткеч булып акыл үсеше тора. Киң мәгънәдә акыл үсеше төп танып белү процессы үсеше буларак аңлатыла.Тар мәгънәдә – акыл сәләте үсеше. Акыл сәләте үсеше баланың әйләнә-тирәдә ориентирлашу ысулларын гомумиләштерүне күз алдында тота.

3-4 яшьлек балалар үсешендә сәнгать эшчәнлеге мөһим урын алып тора. Әлеге эшчәнлек баланың предмет турындагы күзаллауларына бәйле. Бу яшьтә күзаллаулар формалаша гына башлый. График образлар ярлы. Кайбер балаларның рәсемнәрендә детальләр төшеп кала, ә икенчеләре киресенчә, җентекләп ясый. Балалар рәсемнәрдә төрле төсләр куллана башлый. Кул моторикасын үстерү өчен әвәләү, бармаклар гимнастикасы зур әһәмияткә ия. Кече мәктәпкәчә яшьтәге балалар зурлар җитәкчелегендә гади предметлар әвәләргә сәләтле. Кисеп ябыштыруның (аппликация) кабул итү үсешенә уңай йогынты ясавы билгеле. Бу яшьтә кисеп ябыштыруның иң гади төрләрен башкаралар.

Кече мәктәпкәчә яшьтә балаларның төзү эшчәнлеге, үрнәк буенча һәм уйлап чыгарылган катлаулы булмаган төзелешләр белән чикләнә.

Әлеге яшьтә аерым эшчәнлекләр үсеш ала. Балалар башлангыч эталоннарны (кабул итүнең индивидуаль берәмлекләре) кулланудан сенсор эталоннарга (кабул итүнең эшкәртелгән чаралары) күчәләр. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына балалар предметларның һәм төсләрнең биштән алып җиде төренә кадәр аералар, предметларны зурлыгы буенча дифференциациялиләр, балалар бакчасының төркем бүлмәсе, белем бирү процессын оештырганада, бөтен балалар бакчасы бинасы пространствосында ориентирлашалар.

Хәтер һәм игътибар үсеш ала. Зурлар үтенече буенча балалар 3-4 сүз һәм 5-6 предмет исемен хәтерләрендә калдыралар. Кече мәктәпкәчә яшь ахырына алар яраткан әсәрләрдән өзекләрне истә калдырырга сәләтле. Күрсәтмә-хәрәкәт фикерләве үсеше дәвам итә. Шуның белән беррәттән , кайбер очракларда, теләгән нәтиҗәләрне исәпкә алып, мак-сатчан үрнәк нигезендә ситуация үзгәрә. Мәктәпкәчә яшьтәге балалар предметлар арасындагы кайбер яшерен бәйләнешне билгеләргә сәләтле. Кече мәктәпкәчә яшьтә күзаллау үсеш ала һәм ул бигрәк тә уенда чагылыш таба. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт нормалар һәм кагыйдәләр белән билгеләнә. Максатчан тәэсир итү нәтиҗәсендә, алар үзләренең һәм башка балаларның эшләрен бәяләү өчен нигез булган, чагыштырмача зур күләмдә нормаларны үзләштерә алалар. Балалар арасындагы үзара мөнәсәбәт бигрәк тә уем эшчәнлегендә ачык чагыла. Шулай ук бу яшьтә сайлауга корылган үзара мөнәсәбәт тә күзәтелә. Уенчык сайлауга бәйле конфликтлар килеп чыга. Төркемдә баланың иптәшләре арасында тоткан урыны тәрбияче фикере белән билгеләнә.

Кече мәктәпкәчә яшьтә чагыштырмача гади генә ситуациядә тәртип һәм мотивның бер-берсенә буйсынуы күзәтелә. Тәртип белән аңлы рәвештә идарә итүгә әле нигез генә салына, күп очракта баланың тәртибе ситуатив характерда. Шуның белән беррәттән, сүзле күрсәтмәләр ярдәмендә баланың үз теләген үзе чикләвен күрергә була. Балалар үз мөмкинлекләрен бәяли башлыйлар, ләкин тәрбияче бәяләмәсенә ориентирлашалар.

## 1.3 Программаны үзләштерүнең максатчан юнәлеше

- Бала әйләнә-тирә предметлар белән кызыксына һәм алар белән актив эшли; уенчыклар һәм башка предметлар белән эмоциональ эш итүгә тартыла, үз хәрәкәтләре нәтиҗәсендә нәрсәгәдер ирешүдә үзсүзлелек күрсәтергә омтыла.
- Предметларга карата махсус үзләштерелгән гамәлләр куллана, көнкүреш предметларының (кашык, тарак, карандаш һ.б.) кулланылышын белә һәм алардан файдалана ала. Үз-үзенә хезмәт күрсәтүнең иң гади күнекмәләренә ия; көнкүрештә һәм уенда мөстәкыйль булырга омтыла; пөхтәлек күнекмәләрен күрсәтә.
- Дорфалыкка, саранлыкка карата тискәре мөнәсәбәт белдерә.
- Элементар әдәплелек кагыйдәләрен үти (мөстәкыйль яисә искә төшереп, «рәхмәт», «исәнмесез», «хушыгыз», «хәерле төн» (гаиләдә, төркемдә) дип әйтә; бакчада, өйдә, урамда элементар үз-үзен тоту кагыйдәләре турында беренчел күзаллауларга ия һәм аларны үтәргә тырыша.
- Аралашуда актив сөйләмгә ия; сораулар һәм үтенечләр белән мөрәҗәгать итә ала, зурлар сөйләмен аңлый; әйләнә-тирәдәге предметлар һәм уенчыкларның исемнәрен белә. Сөйләм башка балалар белән аралашуда тулы канлы чарага әверелә.
- Зурлар белән аралашырга омтыла, һәм хәрәкәтләрдә, һәм гамәлләрдә актив рәвештә аларга охшарга тырыша; бала зурлар гамәлләрен кабатлап күрсәтә торган уеннар барлыкка килә. Зурлар тәкъдим иткән уенга эмоциональ тартыла, уен кагыйдәләрен кабул итә.
- Әйләнә-тирә табигать дөньясы белән кызыксына, ел фасылларына кагылышлы күзәтүләрдә кызыксынып катнаша.

- Шигырьләргә, җырларга һәм әкиятләргә, рәсемнәр карауга кызыксыну белдерә, музыка тавышына хәрәкәтләр ясарга омтыла; төрле мәдәният һәм сәнгать әсәрләренә эмоциональ мөнәсәбәтен белдерә.
- Курчак театры геройлары гамәлләрен аңлап күзәтә; театральләштерелгән һәм сюжетлы-рольле уеннарда катнашырга теләк белдерә.
- Продуктив эшчәнлек белән (рәсем ясау, әвәләү, конструкцияләү, аппликация) кызыксына.
- Балага эре моторика хас, ул төрле төрдәге хәрәкәтләрне үзләштерергә омтыла (йөгерү, үрмәләү, атлап чыгу һ.б.). Гади эчтәлекле, катлаулы булмаган хәрәкәтле уеннарда кызыксынып катнаша.
**Вариатив өлеш.**
- Бүтән милләт кешеләренә карата, аларның культурасы, традицияләренә карата баланың хөрмәте арта.
- Бала татар һәм рус телләрендә иркен сөйләшә.
- Балада күрше милләтләр турында белемнәрен арттыру теләге тагын да арта.
- Туган якта яшәүче кошлар, хайваннар, үсемлекләргә карата сакчыл карашлары арта.

## 3. Эчтәлек бүлеге

### 2.1.Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

#### “Иҗтимагый-коммуникатив үсеш” белем бирү өлкәсе

**Максат:** балаларның коммуникатив күнекмәләрне үзләштерүләренә һәм җәмгыять тормышына иң уңайлы юллар белән кереп китүенә ирешү.

**Бурычлар:**

- җәмгыяттә гомумкабул ителгән кагыйдәләр, әхлакый, әдәплелек нормалары турында белемнәрен тирәнәйтү;
- баланың мөстәкыйльлелеген үстерүгә мөмкинчелекләр тудыру;
- олылар һ әм яшьтәшләре белән үзара мөнәсәбәтләр урнаштыруга нигез булдыру.

**Бала гаиләдә һәм җәмгыяттә.**

**Мин образы**. Балаларда мин образын формалаштыруны дәвам итү. Аларга үзләренә кагылышлы мәгълүматларны ( син малай, синең күзләрең соры төстә, син уйнарга яратасың), шулай ук аның үткәне (син кечкенә вакытта йөри, сөйләшә белми идең ), хәзерге вакытта барлыкка килгән үзгәрешләре (хәзер син үзеңне өстәл артында дөрес тота, рәсем ясый, бии, җырлый беләсең, ягымлы итеп сөйләшәсең) хакында һәрвакыт җиткереп тору.

**Гаилә.** Балалар белән аларның гаилә әгъзалары хакында сөйләшү (исемнәрен сорашу, нәрсәләр белән шөгыльләнәләр, балалар белән ничек уйныйлар).

**Балалар бакчасы**. Балаларда балалар бакчасына карата уңай фикер булдыру. Төркемнәрнең матурлыгына, уңайлылыгына (матур уенчыклар, җиһазлар, төсле рәсемле китаплар) игътибарларын җәлеп итү. Уен мәйданчыгының матурлыгына, уңайлылыгына басым ясап, балаларны мәйданчык белән таныштыру. Балаларның игътибарын бүлмә гөлләренең төрлелегенә, матурлыгына юнәлтү . Балаларны төркем тормышына кертеп җибәрү, төркемне чиста, тәртипле итеп тотарга, уенчыкларга, китапларга, җиһазларга сак караш тәрбияләү. Балаларда бердәмлелек хисе булдыру. Балалар бакчасында, мәйданчыкта иркен ориентлаша белү күнекмәләре булдыру. Бакчада эшләүчеләргә карата хөрмәт хисе тәрбияләү.

**Балаларда уен эшчәнлеген устерү**: акрынлап һәр баланың уйнау тәҗрибәсен үстерү; уен иленең яңа мөмкинлекләрен ачу;

Иҗатлылыкка, уен вакытында бер-берсе белән аралашуга кызыксыну уяту; Төрле эмоциональ халәтләрне уен барышында чагылдыра алуларын үстерү;

**Үз-үзеңә хезмәт күрсәтү, мөстәкыйльлек тәрбияләү, хезмәт тәрбиясе:** Гигиена, өстәл артында үз-үзеңне тоту, юына белү кагыйдәләрен камилләштерү; балаларны үзеңнең тышкы кыяфәтеңне пөхтә тотарга, сабын белән чиста итеп юынырга, коры итеп сөртенергә, сөлгеңне урынына элеп куярга, кулъяулыгы, тарак белән кулланырга күнектерү.

Өстәл артында үз-үзеңне тоту күнекмәләре булдыру: калак, чәнечке, салфетка белән дөрес кулланырга, ипине вакламаска, ашаганда сөйләшмәскә, ашамлыкны авызны йомып чәйнәргә өйрәтү. Балаларны дөрес эзлеклелектә мөстәкыйль киенергә, чишенергә өйрәтү, пөхтәлек күнекмәләре булдыру.

**Күмәк эшләрдә катнашу теләге уяту**: уенчыкларны урыннарына алып кую, шөгыльләр өчен пумалалар, әвәләү такталарын әзерләү, эш беткәч урыннарына алып кую, үсемлекләрне карау, себерү , тузан сөртү, эскәмияләрне кардан чистарту кебек эшләрне башкару , ашханәдә кизү тору: салфеткаларны җәю, калаклар тарату. Балаларга олылар хезмәте турында сөйләү , таныш булган профессияләр турында тулырак мәгълүмат бирү (тәрбияче, табиб, сатучы, төзүче, машина йөртүче).

**Куркынычсызлык нигезләре булдыру**.

**Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен**: агач ботакларын сындырмау, яфракларын өзмәү, чәчәкләрне йолкымау, урамдагы песи, этләргә тимәскә кирәклеген аңлату.

**Балалар бакчасында куркынычсызлык кагыйдәләренә**: бер-

береңне этәргә ярамаганлыгына күнектерү; ком баскычтан төшкәндә һәм менгәндә, тотынырга кирәклегенә, сикерергә,, су, кар белән уйнаганда куркынычсызлык кагыйдәләренә күнектерү.

**Юлда куркынычсыз йөрү**. Балаларның тирә-юндә ориентлашу мөмкинлекләрен киңәйтү. Аларны юлда йөрү кагыйдәләре белән таныштыру. Светофорның төсләрен мәгънәсен, җәяүлеләр өчен ясалган юлны машиналар йөри торган юлдан аерырга өйрәтү. Юлны аркылы чыкканда зурларга тотынып чыгарга кирәклегенә төшендерү. Машина йөртүче хезмәте белән таныштыру.

**Үз-үзеңне саклау кагыйдәләре**. Балаларны өйдәге куркыныч булган әйберләр белән таныштыру (кайнар плитә, үтүк, электр тогы, электр приборлары). Уйнаганда вак әйберләрне колакка, борынга тыкмаска, авызга капмаска кирәклеген искәртү. Олылардан ярдәм сорау күнекмәләре булдыру.

## Вариатив өлеш

## «Социальләштерү» белем бирү өлкәсе

«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр системасына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Тирә-юньдәгеләргә карата кызыксыну һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү. Туган телдә ышанычлы аралашу шарт-лары тудыру. Әйләнә-тирә дөнья, туган шәһәр (авыл), респу-блика вакыйгалары турындагы төрле мәгълүмат чыганагы буларак, балаларның өлкәннәр белән аралашуга ихтыяҗын хуплау.

Культуралы аралашу күнекмәләре булдыру (әңгәмәдәше-нең милләтенә карап, ачык йөз белән шул телдә исәнләшү һәм сабуллашу; үтенеч, тәкъдимнәрне әдәпле итеп белдерү; ярдәм, сый-хөрмәт өчен рәхмәт белдерү; яшьтәшенә исеме белән ягымлы итеп эндәшү, килешмәү яки канәгать булмауны әдәпле генә аңлата белү).

Балаларны республиканың истәлекле төп бәйрәмнәре белән таныштыру. Балалар бакчасы тормышы, республикада-гы, илдәге вакыйгаларга мөнәсәбәтле булу хисе тәрбияләү.

Әйләнә-тирә тормыш, әдәби әсәрләр һәм мультфильмнар-ның эчтәлегеннән чыгып, күңеленә ошаган ике-өч бала бе-лән уеннар оештыра; «Чәкчәк пешерәбез» һ. б. типтагы уен күнегүләрендә уен гамәлләрен башкара белергә өйрәтү.

Балаларның тормыш тәҗрибәсен, предметлы-уенлы мохит-не, уйнау культурасын баетып, татар һәм рус халыкларының көндәлек тормышын чагылдыра торган сюжетлы-рольле уен-нар оештыру өчен шартлар булдыру. Балаларга уен өчен мөс-тәкыйль рәвештә милли уенчыклар, бизәнү-ясану әйберләре, киемнәр һ. б. сайларга ярдәм итү.

Персонаж белән бәйләнешкә керүнең беренче тәҗрибәсен (курчак Алсу концерт күрсәтә), өлкәннәр белән аралашу даирәсен киңәйтү (әби авылга кунакка чакыра) юлы белән, сәхнәләштерелгән уеннарга кызыксыну уяту.

Авазлар белән башкарыла торган уен-гамәлләргә җавап бирү, татар композиторлары музыкасы астында һәм яңгы-раган сүзгә (татар поэзиясе һәм кече фольклор әсәрләрен-дәге) хайван һәм кошларга охшатып хәрәкәтләр ясау теләге уяту.

Халык уенчыклары, курчак театры персонажлары, музы-каль уенчыклар (курай, гармун һ . б.) белән күңел ачу уеннары оештыру.

Гаилә әгъзалары (әти-әни, бабай-әби, абый-эне, апа-сеңел), аларның исемнәре, бер-берләрен кайгырту ысуллары турында күзаллаулар формалаштыру; өлкәннәрнең үтенеч һәм йомыш-ларын үтисе, гаилә әгъзалары белән уртак хезмәттә катнашасы килү теләкләрен хуплау. Ата-ана һәм башка якын кешеләргә карата игътибарлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

**“Хезмәт” белем бирү өлкәсе**

“Хезмәт” белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашы-руга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Кече фольклор жанрлары ярдәмендә балаларда хезмәт эшчәнлеге турында кайбер күзаллаулар формалаштыру. Балаларның үз-үзләренә хезмәт күрсәтү һәм хезмәт эшчәнлекләре (хуҗалык-көнкүреш хезмәте, табигатьтәге хезмәт) барышында татар халык мәкальләрен файдалану.

Әти-әниләрнең балалар аңлый торган һөнәрләре (табиб, сатучы, шофёр, төзүче һ.б.) белән таныштыру.

**“Танып- белү үсеше” белем бирү өлкәсе**

**Максат**: иҗтимагый характердагы беренчел күзаллауларга төшендерү, балаларны иҗтимагый мөнәсәбәтләргә кертеп җибәрү.

**Бурычлар:**

- балаларның кызыксынучанлыклары, аң үсеше, танып белү эшчәнлеге формалаштыру,
- иҗат мөмкинлекләренең киңәйтү;
- үзе, башкалар, тирә-юньдәге объектлар турындагы беренчел мәгълүматларның барлыкка китерү,
- туган ил, туган җир төшенчәләрен аңлату.

**Сенсорик үсеш:**

- Тоемлау тәҗрибәсен үстерү, аларны сөйләмдә кулланырга өйрәтү, тоемлауны, образлы күзаллауларны камилләштерү, предметларның төс, форма, зурлык үзенчәлекләрен аерып күрсәтә белүләрен ныгыту, берничә предметны берничә төрле сенсорик билгеләре буенча группалыштыруны ныгыту (зурлык, төс, форма). Предметларны төсләре һәм зурлыгы буенча берләштерүне, 4-5 кисәктән торган рәсемнәрне җыюны камилләштерү.

**Танып белүне, эзләнүчәнлекне үстерү:**

- Күләмле геометрик фигуралар белән конструкцияләү үзенчәлекләренә төшендерү,
- Балаларда өйләр, йөк машиналары, җиһазлар, тау төзү күнекмәләре булдыру,
- Конструкцияләрнең тышкы кыяфәтен үзгәртеп булуын, ком һәм кардан биналар төзегәндә аларның ябышу, берегү үзенчәлекләренә төшендәрү,
- Үзлектән әшләү, иҗатлылык омтылышларын үстерү
- Тирә-юньне үзләштергәндә эзләнүчәнлек эшенә кызыксынучанлыкларын арттыру.

**Элементар математик күзаллауларны формалаштыру:**

- Бер төрле предметларны бер группага җыю, предметларны саны буенча аеру (бер-күп) күнекмәләре булдыру,
- Предметларның капма-каршы билгеләренә балаларның игътибарын җәлеп итү һәм аларны сөйләмдә чагылдыра белергә өйрәтү (зур өй-кечкенә өйчек),
- Предметларны формалары буенча аерырга өйрәтү (шар, куб).

**Вариатив өлеш**

**“Танып белү” белем бирү өлкәсе**

“Танып белү” белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Баланы үзе яши торган урам, шәһәр (авыл) исемнәрен әйтергә өйрәтү. Әйләнә-тирә (шәһәр яки авылның төп объектлары), янәшәдәге предметлар, аларның билгеләнешләре белән таныштыруны дәвам итү. Кешеләр яши торган йортларның төзелеше, өй кирәк-яраклары турындагы кү-заллауларын үстерү.

Балалар бакчасында, өйдә була торган вакыйгаларда (бәй-рәм иртәләрендә, якын кешеләренең һәм яшьтәшләренең ту-ган көннәре һ. б. бәйрәмнәр уңаеннан бүләк әзерләүдә, гаилә бәйрәмнәрендә катнашу һ. б.) актив катнашасы килү теләге уяту.

Үз-үзләрен кунакта, дусларының туган көннәрендә, ха-лык бәйрәмнәрендә, балалар бакчасында әдәпле тоту кагыйдәләренә өйрәтү. Урамда, юлларда, җәмәгать транспортында тәртип кагыйдәләре белән таныштыру.

Балаларда ял (бәйрәм) көннәрен кем белән, кайда (циркта, «Кырлай» аттракцион паркында, үзәк мәйданда, шәһәр урамнарында, шәһәрдән читтә) үткәрүләре турында сөйләргә теләк уяту. Вакыйгаларга уңай эмоциональ мөнәсәбәт чагылышын, алган тәэсирләрен өлкәннәр һәм балалар белән бүлешүгә омтылышларын хуплау.

Туган якның кайбер үсемлекләре: агачлар (каен, имән, чыршы), куаклар (сирень, гөлҗимеш), чәчәк атучы үлән үсемлекләр (тузганак, үги ана яфрагы), бүлмә гөлләре (яран, фикус) белән таныштыру. Бөҗәкләр (күбәләк, камка, энә кара-гы) турындагы күзаллауларын киңәйтү.

Үзләре яшәгән җирлектәге йорт һәм кыргый хайваннар, аларның үзенчәлекләре белән таныштыру эшен дәвам итү. Хайваннар дөньясына, барлык тереклек ияләренә, табигатькә карата кызыксыну уяту. Балаларны тәүлек бүленеше һәм табигатьтәге сезонлы үзгәрешләрне, кешеләрнең ел фасыл-лары белән бәйле хезмәт эшчәнлеген күрә белергә өйрәтү. Әйләнә-тирә табигатьнең матурлыгына (салават күпере, агачлардагы бәс, беренче чәчәкләр күренү һ. б.га) соклана белү күнекмәләре үстерү.

**“Сөйләм үсеше” белем бирү өлкәсе**

**Максат:**

Сөйләм үсеше сөйләм телен аралашу чарасы буларак өйрәтүне һәм актив сүзлекне баетуны, бәйләнешле монологик һәм диалогик сөйләмне, авазлар һәм интонациянең дөрес әйтнлешен, балалар әдәбияты белән таныштыру.

**Бурычлар:**

- Балаларда телнең фонетик, лексик, грамматик төзелеше турында күзаллаулар булдыру;
- Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре булдыру;

**Эш төрләре:**

**Сүзлек запасы булдыру:**

- Балаларны сүзләрнең предметларны, күренешләрне, аларның сыйфатларын, билгеләрен, эш-шөгыльне, фикерне белдерүенә төшендерү.

**Аваз культурасы булдыру:**

-Балаларда ишетеп белү күнекмәләрен үстерү, авазларны дөрес әйтү, интонация, тембр, тон, тавыш көчлелеге турында белемнәрен ныгыту.

**Грамматик төзелеш:**

-җөмләләрдә тиңдәш кисәкләрне, кулланырга өйрәтү.

**Сөйләм телен үстерү:**

- диалогик сөйләмне балаларның аралашуы вакытында үзләренең тәэсирләре, истәлекләре белән бүлешергә күнектерү.

- бәйләнешле монологик сөйләм вакытында бер-береңне бүлдермичә сөйләргә, тыңларга өйрәтү.

**Вариатив өлеш**

**“Сөйләм үсеше” белем бирү өлкәсе**

“Сөйләм үсеше” белем бирү өлкәсе эчтәлеге әйләнә-тирәдәге кешеләрнең үзара мөгамәләсенең конструктив ысул һәм чара-ларын үзләштерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Баланы туган телендә төрле темаларга сөйләшергә, аралашырга өйрәтү; күргәннәре турында күзаллап сөйләргә генә түгел, тормышында булган вакыйгалар, башкарган эш-гамәлләре, үзен кызыксындырган күренеш һәм предметлар, туган як табигате объектлары турында да сөйләргә күнектерү.

Сорауларга җавап бирергә өйрәтү. Үз фикерләрен әйтү, үтенеч һәм тәкъдимнәр белән өлкәннәргә мөрәҗәгать итү ом-тылышларын хуплау.

Таныш булган татар (рус) халык әкиятләреннән өзекләр, шигырьләрне сәхнәләштереп сөйли белү күнекмәләре бирү; 2-3 җөмләдән торган хикәяләр төзергә өйрәтү. Җөмләдәге сүзләрне дөрес бәйләр өчен, кушымчаларны дөрес файдала-нырга өйрәтү.

Балаларның уен барышында үзара мөнәсәбәтләрен (уен-дагы үзләренең эш-гамәлләре турында сөйлиләр, уенчык-лар, аларны алмаштыручы предметларны сүзләр белән атыйлар) җайга салырга булышу. Балаларның сөйләмен барлык белем бирү өлкәләрен үзләштерү өчен кирәкле сүзләр белән баету.

Туган телдәге авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, аваз культу-расы тәрбияләү.

**“Матур әдәбият уку” белем бирү өлкәсе**

“Матур әдәбият уку” белем бирү өлкәсе эчтәлеге бала-ларда китап укуга кызыксыну һәм ихтыяҗ формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Көчле хис-кичерешләр чыганагы булган китапка һәм өлкәннәр белән әдәпле аралашуга кызыксыну формалаштыру.

Яшьтәшләре белән бергәләп тәрбияченең сәнгатьле уку яки сөйләмен тыңлау күнекмәләре булдыру.

Татар халык әкиятләрендә, язучы һәм шагыйрьләрнең әдәби әсәрләрендә вакыйгалар барышын күрсәтмәлелек (уенчыклар, рәсемнәр, хәрәкәтләр) ярдәмендә күзәтергә, аларның эчтәлеген сүзләр, хәрәкәтләр, ишаpәләр белән белдерергә өйрәтү. Уен гамәлләрендә катнашасы килү теләге булдыру, кыен булмаган сорауларга җавап бирергә, персонажларга үз мөнәсәбәтен белдерергә, кара-каршы сөйләшүләр алып барырга күнектерү. Әдәби әсәрләргә карата хисси кичерешләр булдыру, әдәби сүзгә кызыксыну уяту.

Китаптагы иллюстрацияләрне караганда, әдәби әсәр герой-ларын һәм аларның гамәлләрен танырга булышу. Татар халык авыз иҗаты үрнәкләре (юаткычлар, әйтемнәр, бармак уеннары) белән таныштыру. Кече фольклор формаларын көндәлек тор-мышта куллануны хуплау.

**“Сәнгати-нәфәсәти үсеш” белем бирү өлкәсе**

**Бурычлар.**

- Сәнгать әсәрләрен (сүз сәнгате, рәсем сәнгате, музыканы), табигать дөньясын, матур әдәбиятны, фольклорны күзаллауны үстерү.
- Балаларга сәнгатьнең төрләре турында беренчел мәгълүматлар бирү.

**Рәсем ясау:**

- Балаларның эстетик күзаллауларын, тирә-юньнең, уенчыкларның, табигатьнең матурлыгын күрә белү үзенчәлекләрен үстерү;
- Кул хәрәкәтләренең төгәл координациясен үстерә, кул мускулларын ныгыту

**Әвәләү:**

- Пластилин, үзле балчык, тозлы камырның үзлекләре, алар белән эшләү үзенчәлекләрен өйрәтү, кулның вак моторикасын үстерә, хәрәкәтләрне төгәл ясарга күнектерү.

- Берничә кисәктән торган предметларны берләштереп әвәләргә өйрәтү;

**Кисеп ябыштыру:**

- детальләрне кәгазь битенә урнаштырырга, билгеле бер эзлеклелектә ябыштырырга өйрәтү;

- балаларның төс, форма, зурлык турындагы күзаллауларын үстерү

**Музыка эшчәнлеге**

**Бурычлар:**

- Музыкаль әсәрне ахырга кадәр тыңларга өйрәтү.

- Таныш җырларны тану күнекмәләре булдыру.

- Музыканың характерын (күңелле, дәртле, салмак) аерырга, бер темпта башкалардан калышмыйча җырларга өйрәтү.

- Бию күнегәләрен: парлап әйләнү, чиратлаштырып тыпырдату күнекмәләре булдыру.

- Музыкага кушылып, уен коралларында уйнау күнекмәләре булдыру.

**Вариатив өлеш**

**Сәнгати-нәфәсәти үсеш белем бирү өлкәсе**

“Сәнгати-нәфәсәти үсеш” белем бирү өлкәсе эчтәлеге балалар-да әйләнә-тирәдәге матурлыкка кызыксыну уятуны һәм үз-үзләрен күрсәтү ихтыяҗларын канәгатьләндерүне форма-лаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Нәтиҗәле эшчәнлек төрләрен үстерү

Рәсем ясау

Балаларга рәсемнәрдә әйләнә-тирә табигатьнең матур-лыгын (миләш тәлгәшләре, җиргә коелучы төрле төстәге яф-раклар һ. б.ны) сурәтләп бирергә тәкъдим итү.

Балаларны сәнгать әсәрләрен кабул итәргә әзерләү. Татар декоратив-гамәли сәнгатенең иң гади бизәк элементлары һәм алар белән бизәлгән көнкүреш предметлары белән таныштыру. Сәнгать әсәрләренең матурлыгына уңай эмоциональ караш тәрбияләү.

Балаларны декоратив эшчәнлеккә тарту: милли орнамент элементларын (лалә, күкчәчәк, кыңгырау чәчәк, яфраклар һ. б.ны) буяу ысулларын күрсәтү. Сурәтләнә торган предметка туры килгән төсне сайлап алырга өйрәтү.

Татар орнаментына хас булган төс исемнәрен (кызыл, зәңгәр, яшел, сары, ак, кара) белүләрен ныгыту. Бер, ике яки берничә төсне кулланып, сурәтләр тасвирларга өйрәтү.

Балаларны төрле юнәлештә туры сызыклар (кыска, озын, вертикаль, горизонталь, авыш) сызарга өйрәтү. Төрле форма-дагы (түгәрәк, турыпочмаклы) предметлар сурәтләүгә өйрәтү. Гади сурәтләр (Казан сөлгесе, тастымал, кечкенә тәлинкә һ.б.) иҗат итү күнекмәләрен үстерү.

Татар гамәли сәнгате мотивлары буенча коллектив ком-позицияләр төзегәндә, өлкәннәр белән бергәләп эшләү тәҗ-рибәсе формалаштыру.

**Әвәләү**

Әвәләү эшчәнлегенә кызыксыну уяту. Балчык, пластилин, тозлы камырның үзлекләре һәм аларны әвәләү ысуллары ту-рындагы күзаллауларын ныгыту.

Балчык, пластилин кисәкләрен туры һәм әйләнүле хәрәкәт белән әвәләү; ике кулның уч төпләре белән басып, шарны яссыландыру. Уйнау өчен гади генә формалар – коймак, кабартма, мич күмәчләре әвәләргә дәртләндерү.

Балчык, камыр белән пөхтә эш итү күнекмәләрен ныгыту; әвәләп ясалган әйберләрне һәм кисәкләрне әвәләү тактасына кую.

Әвәләнгән фигуралардан күмәк композиция төзергә тәкъдим итү (подностагы пәрәмәчләр, чәй сервизы һ. б.). Күмәк эшчәнлекнең нәтиҗәсен күреп, шатлану хисләре тудыру.

**Кисеп ябыштыру**

Балаларны аппликация сәнгатенә тарту, бу эшчәнлек төренә кызыксыну уяту. Татар орнаментының алдан ук әзерләнгән чәчәк-үсемлек формаларын (лалә, кыңгырау чәчәк, ромашка (акчәчәк), гөлҗимеш, миләш тәлгәшләре һ.б.) башта кәгазь битенә таратып салырга, аннары тар кәгазь кисәгендә билгеле бер тәртиптә тезеп куярга, уртага, квадрат, түгәрәк кырыйла-рына урнаштырырга өйрәтү.

Татар декоратив-гамәли сәнгате мотивлары буенча шәхси һәм күмәк композицияләр иҗат итү күнекмәләрен үстерү.

**Сынлы сәнгатькә тарту**

Татар халык декоратив-гамәли сәнгате әсәрләренә (милли киемдәге курчак, Шәмәрдән, Актүбә уенчыклары һ. б.га) кы-зыксыну уяту.

Балаларга якын, таныш булган хис-кичерешләр чагылдырылган сынлы сәнгать әсәрләренә, халык әкиятләре, татар язу-чылары һәм шагыйрьләренең хикәя-шигырьләреннән торган рәсемле китапларга уңай эмоциональ мөнәсәбәт булдыру.

**“Музыка” белем бирү өлкәсе**

“Музыка” белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның музыкальлекләрен, музыканы хис-тойгы белән кабул итү сәләтләрен үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татар халык музыкасы һәм татар композиторларының музыкасына, музыка астында башкарылган хәрәкәт импро-визацияләренә (үзлектән яки тәрбияче ярдәмендә) уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

Курай, тальян гармун һ. б. музыкаль инструментларны яңгырау тавышыннан таный белү күнекмәләре формалаштыру.

Татар биюләренә хас булган гади хәрәкәтләр («аяк очларында атлап йөрү», «бер аяк белән тыпырдау», «борма» (гади вариант), «култыклашып әйләнү» һ. б.) белән таныштыру. Биисе килү теләге уяту.

Музыканы балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә фай-далану. Кәефкә туры килерлек һәм хис-кичерешләргә булыш-лык итәрлек музыка астында матур әдәбият һәм сынлы сәнгать әсәрләре кулланып, катнаш музыкаль шөгыльләр үткәрү.

**“Физик үсеш” белем бирү өлкәсе**

**Максат:** балаларда физик күнегүләргә карата кызыксыну уятуга, бербөтен физик үсешне тәэмин итүгә, сәламәт яшәү рәвеше нигезен булдыруга юнәлтелгән.

**Бурычлар:**

- Физик сыйфатларын үстерү (тизлек, көч, сыгылмалылык, түземлелек, координация.
- Хәрәкәтләнү эшчәнлеге тәжрибәсен туплау, берләштерү (төп хәрәкәтләнү күнегүләрен истә калдыру).
- Балаларда хәрәкәтләнүгә, активлылыкка, физик камиллелеккә ихтыяҗ тудыруны будыру.

**Эш төрләре:**

- Иркенләп йөгерү, йөреш осталыкларын үстерү, түгәрәкә тезелә белергә өйрәтү.
- Утырган җирдән, баскан килеш, йөргәндә, күнегүләр ясаганда дөрес асанка тоту, әйләнә-тирәдә ориентлаша белергә өйрәтү.
- Ике аякта сикерә, туны этеп җибәрә белергә өйрәтү, шуышу осталыкларын арттыру.
- Сигналны ишетә, күрә белергә өйрәтү.
- Хәрәкәтле уеннар вакытында кулланылучы төп хәрәкәтләрне истә калдыру,
- Үз хәрәкәтләрен башкалар белән бергә эшләргә өйрәтү, Хәрәкәтләрне бергәләп башлау, бетерү, гади күнегүләрне үзлегеннән эшләү күнекмәләре булдыру.
- Катлаулы булмаган кагыйдәлргә нигезләнгән хәрәкәтле уеннар уйнау, уен барышында матур итеп хәрәкәтләнергә күнектерү, шуышу, үрмәләү, җитезлек күнекмәләре булдыру.

**Вариатив өлеш**

**Физик үсеш**

**“Сәламәтлек” белем бирү өлкәсе**

“Сәламәтлек” белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның сәламәтлекләрен саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен саклау һәм ныгыту; учреждение төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш торышы үзенчәлекләрен, шулай ук төбәкнең климатик шартларын һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын системалы чыныктыруга, хәрәкәтләрнең төп төрләре формалашуга һәм камилләшүгә шартлар тудыру.

Культура-гигиена процедураларының төп алгоритмнары белән таныштыру.

Балаларны гигиена процедураларын аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә башкарырга гадәтләндерү. Сабынны дөрес куллану, кулларны, битне, колакларны чиста юу; юынгач коры итеп сөртенү, сөлгене урынына элү, тарак һәм кулъяулык куллану күнекмәләрен формалаштыру.

Өстәл янында үз-үзеңне дөрес тотуның иң гади күнек-мәләрен формалаштыру: аш һәм чәй кашыкларын, чәнечке, салфетканы дөрес куллану.

Ипине вакламаска, азыкны түкми-чәчми ашарга, ризык-ны авызны ябып чәйнәргә, ашап туйгач рәхмәт белдерергә күнектерү.

Милли ризыклар: токмачлы аш, шулпалы пилмән, чумар ашы, сөтле чәй һ. б. белән таныштыру.

Файдалы һәм зарарлы азык-төлек турында күзаллау бул-дыру; яшелчәләр һәм җиләк-җимеш, кеше организмы өчен файдалы сөт ризыклары: каймак, катык, эремчек һ. б. белән таныштыру.

Сәламәтлекнең әһәмиятен аңлату, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү өчен шартлар тудыру. Үз сәламәтлегеңә һәм якын кешеләреңнең сәламәтлегенә сакчыл караш тәрбияләү.

Көндәлек тормышта гигиена күнекмәләрен үтәүгә һәм пөхтәлек булдыруга ихтыяҗ формалаштыру.

**“Физик культура” белем бирү өлкәсе**

“Физик культура” белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда физик культура шөгыльләренә кызыксыну һәм аңлы караш, гармонияле физик үсеш формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Хәрәкәтле уеннарда балаларның хәрәкәт активлыгын формалаштыру.

Шуышу, үрмәләү күнекмәләрен үстерүче уеннарны, тупны ыргыту һәм тотып алу уеннарын хуплау. Акрынлап катлаулы-рак кагыйдәле һәм хәрәкәтләр алмашынулы уеннар уйнарга өйрәтү.

**Уен үрнәкләре**

Йөрүле һәм йөгерүле уеннар: «Миңа таба йөгерегез», «Песи һәм тычканнар», «Маэмай», «Флаг янына йөгерегез», «Аю урманында», «Кетәклектә төке», «Атлар», «Такси», «Түгәрәктә».

Сикерүле уеннар: «Инеш аша», «Күбәләкне тот», «Чып-чыклар һәм песи», «Түмгәктән түмгәккә».

Шуышулы, үрмәләүле уеннар: «Тавык һәм чебиләр», «Йорт куяннары».

Тупны ыргыту һәм тотып алу уеннары: «Туплар», «Кы-зыл, зәңгәр...», «Төз ыргыт», «Тот, ыргыт, төшермә...».

Әйләнә-тирәдә ориентлашуга уеннар: «Чыпчыклар һәм автомобиль», «Трамвай», «Үз төсеңне тап», «Үз өеңне тап».

Аз хәрәкәтле уеннар: «Машина килә», «Куык», «Тигез юл буйлап», «Кошчыклар».

**“Куркынычсызлык” белем бирү өлкәсе**

“Куркынычсызлык” белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын форма-лаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру

Балаларны балалар бакчасында үз-үзләрен тотуның иң гади кагыйдәләре белән таныштыру.

Тормышта була торган куркыныч чыганаклары (кайнар су, ут, кисә һәм чәнчи торган очлы предметлар, электр приборла-ры һ. б.) турында беренчел күзаллаулар булдыру.

Бассейн һәм сулыкларда коенганда сак булырга күнектерү. Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру

Балаларны юлларның машиналар һәм җәяүлеләр йөри торган өлешләре (тротуар) белән таныштыру; светофорның кы-зыл, сары һәм яшел төсләренең мәгънәләрен аңларга ярдәм итү. Күрү сигналлары ярдәмендә йөрергә өйрәтү.

Юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү өчен кирәкле булган ситуа-ция һәм объектларны аерып карап, урам, транспорт чаралары турында бербөтен күзаллау формалаштыру.

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы 105

Хәрәкәт итү чараларының атамалары һәм аларны файда-лану максатлары белән таныштыру. Җиңел һәм йөк машиналарының охшаш һәм аермалы якларын табарга, мөһим детальләрен (автомобильдә: кабина, руль, тәгәрмәчләр һ. б.), тору урынын (тәрәзә артында, биек, ерак) әйтә белергә өйрәтү. Хәрәкәт итү чараларының (трамвай, троллейбус, автобус) кайбер охшаш якларына игътибар итәргә, аларны аерым үзенчәлекләре, бурычлары буенча төркемли белергә күнектерү.

Транспорт төрләре (җир өсте, су, һава һ. б.) турында берен-чел күзаллаулар булдыру.

Тавыш чыганагының (хәрәкәт итә торган транспорт, авто-мобиль сигналы, светофорның яшел төсе вакытындагы тавыш сигналы һ. б.) урынын билгели белү, төрле яңгырашлы тавыш-ны кабул итү, хәрәкәт итүче самолёт, поезд, трамвай һ. б. ның тавышларын аера белү күнекмәләрен үстерү. Ишетү игътибар-лылыгын үстерү.

Өлкәннәр хезмәте (машина йөртүче, ЮХИДИ инспекторы, кондуктор (билет сатучы) һ. б.) турында күзаллау формалаш-тыру, аларның эш-гамәлләренә һәм эш нәтиҗәләренә игъти-бар итү.

«Автобус», «Трамвай», «Такси» һ. б. сюжетлы-рольле уен-нар үсеше өчен предметлы-уенлы мохит булдыру; балаларга образлы уенчыкларны, аларны алмаштыручы предметлар-ны, уен мохите тудыра торган модульләрне иркен куллану мөмкинлеге бирү.

Сюжетлы-рольле уеннарны, яки шәхси, аерым бер уенны мөстәкыйль оештыруны хуплау.

Балалар арасында роль алу, рольләр бүлешү, уеннар-да берләшә белү һәм рольдә аралашу осталыкларын үстерү; җәмәгать транспортында аралашу культурасы белән бәйле рольле репликаларны хуплау.

Балаларның дидактик материал белән булган мөстәкыйль уеннарына шартлар тудыру. Су һәм ком белән (көймәчекләр җибәрү, юллар төзү һ. б.) уйнауларны хуплау. Хәрәкәтле уен («Чыпчыклар һәм автомобиль», «Поезд» һ. б.) кагыйдәләрен үтәргә өйрәтү.

Өч тәгәрмәчле велосипедта турыга, түгәрәк буйлап, боры-лышлар ясап йөрергә өйрәтү.

Әдәби әсәрләр эчтәлеген балаларның үз тәҗрибәләре, көндәлек тормышлары һәм әйләнә-тирәләре белән бәйли белүләренә ирешү. Баланың «Ә минем әтиемдә мондый машина бар» тибындагы җөмләләренә актив җавап бирү.

Балаларның инициативалы сөйләмен үстерү, хәрәкәт итү чаралары турында күзаллауларын киңәйтү һәм ачыклау мак-сатыннан, мөстәкыйль карау өчен төрле рәсемле китаплар, реклама буклетлары, техник уенчыклар тупланмасын карарга мөмкинлек бирү; балаларның сорауларын хуплау.

Әйләнә-тирәдә гади закончалыклар һәм бәйләнешләр бу-луына игътибар итү, мәсәлән, әгәр караңгы икән – ут кабызырга, урамда тайгак икән – кеше үтеп йөри торган җирләрдә ком сибәргә һ. б.

**Экологик аң алшартларын формалаштыру**

Табигатьтә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре белән таныштыру. Табигатьтә куркыныч тудыру чыганаклары (таныш булмаган хайваннар, бөҗәкләр, үсемлек җимешләре, сулыклар һ. б.) турында беренчел күзаллаулар формалаштыру.

## 2.2 Белем бирү эшчәнлегенең комплекслы-тематик планы
## Комплекслы-тематик план. Икенче кечкенәләр төркеме.

| Проект темалары | Бурычлар | Йомгаклау чаралары |
|---|---|---|
| Сау бул, җәй, исәнме, бакча! (августның 4 нче атнасы – сентябрьнең 1 нче атнасы) | Балаларда балалар бакчасына кайтуга карата шатлык уяту. Балалар бакчасы белән якынтирәлек буларак таныштыруны дәвам итү: бакча хезмәткәрләренең профессияләре (тәрбияче, тәрбияче ярдәмчесе, музыка җитәкчесе, табиб, ишегалды себерүче), предметлы тирәлек, бакчада үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләр. Төркемнең әйләнәтирә мохите белән, бакча бүлмәләре белән танышуны дәвам итү. Уенчыкларны карарга, аларның формасын, төсен, төзелешен әйтергә тәкъдим итү. Уен вакытында балаларны бер-берсе белән таныштыру (әгәр инде таныш булсалар, берберләрен искә төшерергә булышу). Балалар арасында дустанә мөнәсәбәт формалаштыру (коллектив белән сәнгати эш, дуслык турында җыр, уртак уеннар). | Балалар бакчасы хезмәткәрләре ата-аналар белән берлектә оештырган «Балалар бәйрәме». |
| Көз (сентябрьне ң 2 – 4 нче атналары) | Балаларның көз турында (табигатьтә, кешеләрнең киемнәрендә, балалар бакчасы участогында ), уңыш җыю, кайбер яшелчәләр, җимешләр, җиләкләр, гөмбәләр турында күзаллауларын киңәйтү. Авыл хуҗалыгы һөнәрләре белән (тракторчы, сыер савучы һ.б.) Таныштыру.Табигатьтә үз-үзеңне тоту куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән таныштыру. Табигатькә сак караш тәрбияләү. Һавада йөргәндә балаларга көзге яфраклар җыярга һәм аларны карарга тәкъдим итү. Көз турында шигырьләр өйрәнү. Көзге табигатьнең матурлыгын күрә белү сәләтен үстерү, һава торышын күзәтүләр алып барырга өйрәтү. Йорт хайваннары һәм кошлары турында белемнәренкиңәйтү. Урман җәнлекләренең һәм кошларының тәртибендәге көзге үзенчәлекләр белән таныштыру. Көз темасына рәсемнәр, аппликацияләр ясарга һәм әвәләп ясарга теләк уяту. | «Көз» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Мин һәм минем гаиләм (октябрьнең 1–2 нче атналары) | Сәламәтлек һәм сәламәт яшәү рәвеше турында башлангыч күзаллаулар формалаштыру. «Мин» образын формалаштыру. Үзеңнең йөзең һәм тәнең турында кайгырту буенча элементар күнекмәләр формалаштыру. Үзенең тышкы кыяфәте турында күзаллау тудыру. Гендер күзаллауларын үстерү. Үзенең исемен, | Сәламәтлек көне. Спорт күңел ачулары. |

| | | |
|---|---|---|
| | фамилиясен, гаилә әгъзаларының исемнәрен атарга теләк уяту, үзе турында беренче затта сөйләргә өйрәтү. Үз гаиләсе турында күзаллауларын баету. | |
| Минем өем, минем шәһәрем (октябрьнең 3 нче атнасы — ноябрьнең 2 нче атнасы) | Йорт белән, йорт кирәк-яраклары, җиһазлар, көнкүреш приборлары белән таныштыру. Туган шәһәр (авыл), аның атамасы, төп истәлекле урыннары белән таныштыру. Транспорт төрләре, шул исәптән шәһәр транспорты, шәһәрдә үзеңне тоту кагыйдәләре, элементар юл хәрәкәте кагыйдәләре, светофор, җир өсте һәм җир асты кичүләре (ата-аналар белән үзара бәйләныш) белән таныштыру. «Шәһәр» профессияләре (милиционер, сатучы, чәч кисүче, табиб, машина йөртүче, автобус шоферы) һөнәрләре белән таныштыру. | Юл хәрәкәте кагыйдәләре буенча сюжетлы-рольле уен. |
| Яңа ел бәйрәме (ноябрьнең 3 нче атнасы – декабрьнең 4 нче атнасы) | Балаларның турыдан-туры укыту өлкәсендә дә, мөстәкыйль эшчәнлегендә дә Яңа ел һәм Яңа ел бәйрәме тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белүтикшеренү, продуктив, музыкаль-сәнгати, укулар) оештыру. | Яңа елга багышланган балалар бәйрәме (утренник). |
| Кыш (гыйнварның 1–4 нче атналары) | Кыш турында күзаллауларны киңәйтү. Кышкы спорт төрләре белән таныштыру. Кышын үз-үзеңне тоту иминлеге турында күзаллау формалаштыру. Су һәм боз белән экспериментлар ясау барышында тикшеренү һәм танып белү кызыксынуы формалаштыру. Табигатькә сак караш, кышкы табигатьнең матурлыгын күрә белү сәләтен тәрбияләү. Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында (һава үзгәрешләре, кыш көне үсемлекләр, җәнлекләр һәм кошларның үз-үзен тотуы) күзаллауларны киңәйтү. Һәрвакыт кыш була торган урыннар турында беренчел күзаллаулар формалаштыру. Балаларның индивидуаль һәм яшь үзенчәлекләренә туры китереп, турыдан-туры укыту һәм мөстәкыйль эшчәнлекнең төрле төрләре вакытында алган тәэсирләре белән уртаклашу теләге тудыру. | Балалар иҗаты күргәзмәсе. «Кыш» бәйрәме. |
| Ватанны саклаучылар көне (февральнең 1–3 нче атналары) | Патриотик тәрбияне гамәлгә ашыру. «Хәрби» һөнәрләр белән таныштыру. Ватанга мәхәббәт тәрбияләү. Беренчел гендер күзаллаулары формалаштыру (малайларда көчле, кыю булу, Ватанны саклаучылар булырга омтылу хисләре тәрбияләү). | Ватанны саклаучылар көненә багышланган бәйрәм. |
| 8 Март (февральнең 4 нче атнасы - мартның 1 нче атнасы) | Гаилә һәм әниләргә, әбиләргә мәхәббәт темасы тирәсендә балалар эшчәнлегенең барлык төрләрен (уен, коммуникатив, хезмәт, танып белү-тикшеренү, продуктив, музыкаль-сәнгати, | 8 Март бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе, күңел ачулар, |

| | | |
|---|---|---|
| | укулар) оештыру. Тәрбиячеләргә карата хөрмәт тәрбияләү. | коллектив иҗат, балалар уены. |
| Халык мәдәнияте һәм традицияләр е белән танышу (мартның 2– 4 нче атналары) | Халык уенчыклары турында күзаллауларны киңәйтү (Дымково уенчыгы, матрешка һ.б.). Халык кәсепләре белән таныштыру. Халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам итү. Фольклорны балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә файдалану. | Фольклор бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Яз (апрельнең 1–4 нче атналары) | Яз турында күзаллауларны киңәйтү. Табигатькәсаккараш, язгытабигатьнең матурлыгын күрә белү сәләтен тәрбияләү. Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында (һава үзгәрешләре, яз көне үсемлекләр, җәнлекләр һәм кошларның үз-үзен тотуы) күзаллауларын киңәйтү. Табигатьтәге иң гади бәйләнешләр турында күзаллауларны киңәйтү (җылытты — үләннәр үсеп чыкты һ.б.). Балаларның яз турында тәэсирләрен сәнгати эшчәнлекнең төрле төрләрендә чагылдыру теләге уяту. | «Яз» бәйрәме. Балалар иҗаты күргәзмәсе. |
| Җәй (майның 1–4 нче атналары) | Балаларның җәй турында, сезонлы үзгәрешләр турында (табигатьтәге үзгәрешләр, кешеләр киемендә, балалар бакчасы участогында) күзаллауларын киңәйтү. Җимеш һәм яшелчә бакчасы үсемлекләре турында элементар күзал-лаулар булдыру. Су һәм ком белән эксперимент барышында тикшеренү һәм танып белү кызыксынуын формалаштыру. Табигатькә сак караш, җәйге табигатьнең матурлыгын күрә белү сәләтен тәрбияләү | «Җәй» бәйрәме. |

### 2.3 Гаилә белән үзара бәйләнеш.

Хәзерге фән һәм практика баланың шәхесен формалаштыруда гаиләнең уникаль роль уйнавын исбат итә. Беренче социальләшү гаиләдә башлана, баланың дөньяга, үзенә, башка кешеләргә карашы, мөнәсәбәте формалаша. Ата-аналарның кайгыртучанлыгы балада аның үз-үзенә ышанычын тудыра, башка кешеләр белән түземлек, үзара хөрмәт принциплары нигезендә үзара мөнәсәбәткә керергә әзер торырга ярдәм итә.Ата-ананың тәрбия һәм белем бирү эшчәнлегендә катнашу мөмкинлеге булу бик зур әһәмияткә ия. Хәзерге заман балалар бакчасы ата-аналарга психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтүче учреждение буларак та хезмәт итә. Шул ук вакытта гаилә дә үзара хезмәттәшлек итәр өчен педагогларны өзлексез үсешкә рухландыра. Түбәндәге бурычларны үтәмичә, максатка ирешү мөмкин түгел:

- гаилә белән партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру;
- бакчада ата-анага бала тормышында катнашу өчен шартлар тудыру;
- бала тәрбияләүдә ата-аналарга психологик ярдәм күрсәтү;
- гаиләләр белән үзара аралашуда педагогик компетентлыкны өзлексез күтәрү.

**Гаилә белән үзара бәйләнеш принциплары.**

**1. Психологик уңайлык (комфорт) принципы** – ата-аналар белән аралашуда җылы атмосфера булдыру, һәр гаиләнең ихтыяҗын, социаль-психологик характеристикасын исәпкәалу. Ата-ана белән үзара ышанулы мөнәсәбәт ул – хөрмәт, диалогка омтылу, игътибарлылык, ихласлылык. Балага һәм аның якыннарына карата тәрбиягенең игелеклелеге һәм ачыклыгы ата-ана

ягыннан уңай кабул ителә. Ата - аналарның бакчада балалары шат булса, алар тәрбиячеләргә сораулар белән мөрәҗәгать итәләр. Ата-аналарның бала өчен балалар бакчасының уңайлы, куркынычсыз, файдалы булуын күрү генә түгел, ә балаларның үсешен күрүләре дә әһәмияткә ия. Тәрбияченең баланың яшь үзенчәлеген, психологиясен, үсеш кризисын белүе, ата-ананы тынычлындырып, кирәкле сүзләр таба белүе, алар белән ягымлы мөгаләмәдәге әңгәмәдәшче булуы мөһим.

**2. Эшчәнлек принцибы**. Белем һәм тәрбия бирү процессында балалар бакчасы һәм ата-аналар арасындагы бәйләнештигез хокуклы партнерлар сыйфатына корылган. Партнерлык процессы катлаулы: танышу, стереотипларның җимерелүе һәм үзара аңлашу урнашу,бала тәрбияләүдә бер үк максатны күздә тоту. Педагогның һәм балалар бакчасының позитив имиджы булуы мөһим.

**3. Бербөтенлек принцибы** – тәрбия һәм белем бирүдә гаилә һәм җәмгыять институтларының аерылгысыз бербөтен булуына нигезләнгән. Әлеге принцип бала тәрбияләүдә гаилә белән балалар бакчасының эш стратегиясен билгели. Җәмгыяти тәрбиянең нигезе ул - балага социаль таләпләр системасы кую. Ата-аналарның тәрбияви тәэсире булып, балага карата мәхәббәт, аны куркынычсызлык белән тәэмин итү, аны ничек бар шулай кабул итү тора.

**4. Минимакс принцибы** – һәр гаиләгә дифференциальякынкилү, ата-аналар белән эчтәлекле, тактлы аралашу. Ата-аналар белән танышкач, педагог һәр гаиләнең үзенчәлеген ачыклый, аларның активлыгын күтәрү өчен планлы рәвештә шартлар тудыра.

**5. Вариативлык принцибы** – ата-аналарга тәрбия һәм белем бирү процессына кушылу һәм аралашуның формаларын тәкъдим итү: традицион һәм традицион булмаган, шәхси һәм төркемләп, дистанцион һәм кара-каршы аралашу.

**6. Өзлексезлек принцибы** өйдә һәм балалар бакчасында тәрбия бирүнең өзлексез баруын күз алдында тота.

**7. Иҗадилык принцибы** – тәрбия һәм белем бирү процессында барысына да иҗадилык күрсәтергә мөмкинлек ачу.

**Ата-аналар белән үзара бәйләнеш формалары.**

**1. Мәгълүмати чаралар** – (телдән журнал, реклама буклеты; балаларга тәрбия һәм белем бирү сораулары буенча мәгълүмати белешмә хезмәте; СМИ да чыгышлар; мәгълүмати кәрзиннәр, хатлар; күрсәтмә психо-педагогик пропаганда һ.б.)

**2. Оештыру эшләре** – (ата-аналар җыелышы; анкеталар тутыру; җәмгыяти ата- аналар оешмаларын төзү; коференцияләр, ата-аналар белән берлектә педсоветлар; брифинглар һ.б.)

**3. Культура-агарту чаралары** – (ата-аналар мәктәбе; консультацияләр; тематик очрашулар; матур әдәбият буенча тематик күргәзмәләр оештыру; тренинглар; семинарлар; әңгәмә; дискуссияләр; ата-аналар кунакханәсе; түгәрәк өстәл һ.б.)

**4. Оештыру-эшчәнлек** – (ата-аналар белән берлектә үткәрелгән балаларның үсеш мониторингы, берләштерелгән ата-ана-бала проекты; күргәзмәләр; вернисажлар; мастер-класслар; балалар, педагоглар, ата-аналар иҗаты; гаилә портфолиосы ясау; иҗади эшчәнлек өчен табигый һәм ташландык материаллар җыю; балалар бакчасын ремонтлауда һәм яшелләндерүдә катнашу; балаларның бакчадагы тормышын сурәтләгән буклет, видеофильмнар әзерләү, журналлар чыгару;бакчада үткәрелгән чаралар турында фотоматериалларны электрон җибәрүдә булышу; үстерешле предметлы тирәлекнең сыйфатын тикшерүдә катнашу һ.б.)

**5. Ата-аналарның педагогик процесста катнашуы** – (ата-аналар катнашы белән шөгыльләр; балаларга әкиятләр уку; балалар белән төрле темага әңгәмәләр кору; ата-аналар катнашы белән сәхнәләштерү; саф һавада йөргәндә, экскурсияләргә барган балаларны озату; Ачык ишекләр, Сәламәтлек көнендә, Шәфкатьлелек марафонында катнашу һ.б.)

**Гаилә белән үзара бәйләнеш буенча перспектив план**.

**Максат:** педагоглар, ата-аналарның берләшүе һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларның ориентлашу кыйммәтләре формалашуга бердәм юнәлешен булдыру.

| Ай исемнәре | Чаралар |
|---|---|
| Сентябрь | 1.Ата-аналар җыелышы: “3-4 яшьлек балаларның яшь үзенчәлеге”<br>2.Ата-аналар почмагына консультация “3-4 яшьлек балаларның үсеш үзенчәлекләре”<br>3.Әңгәмә: “Бала һәм ата-ана”<br>4.Сәламәтлек почмагына консультация: “Көз.Витаминлы календарь” |
| Октябрь | 1.Гаилә клубы “Җәзасыз гына буламы?”<br>2.Ата-аналар почмагына консультация: “Мактаргамы, ачуланыргамы?”<br>3.Әңгәмә: “Шаярма” |
| Ноябрь | 1.Консультация: “Балаларны юл кагыйдәләренә өйрәтүнең мөһимлеге”<br>2.Консультация: ”Бала еш ялганлыймы?”<br>3.Әңгәмә: “Гадәттән тыш хәлләрне җиңәргә балага ничек булышу?” |
| Декабрь | 1.Консультация: “Балаларыгызга нинди уенчыклар кирәк?”<br>2.Консультация: “Игътибар! Кыш килеп җитте!”<br>3.Ата-аналар почмагына: “Юл хәрәкәтләре буенча ата-аналарга белешмә” |
| Гыйнвар | 1.Консультация: “Балалар сорауларына ничек җавап бирергә?”<br>2.Ата-аналар почмагына консул-я: “Балалар куркуы бөтен тормышны бозарга мөмкин” |
| Февраль | 1.Ата-аналар җыелышы: “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләүдә гаиләнең роле”<br>2.Санбюллетень: «Күңелле ингаляция”<br>3.Әңгәмә: “Гиперактивлык. Аның белән ничек көрәшергә?” |
| Март | 1.Ата-аналар почмагына консул-я: “Бәла туса, нишләргә?”<br>2.Консультация: “Игътибарны үстерү өчен уеннар”<br>3.Әңгәмә: “Әгәр бала игътибарсыз икән”<br>4.Санбюллетень: «Яз.Витаминлы календарь» |
| Апрель | 1.Консультация: “Балалар мульфильмында өлкәннәр тормышы”<br>2.Консультация “Балалар травматизмын булдырмау чаралары”<br>3.Әңгәмә: “Баланың аң үсеше” |
| Май | 1.Ата-аналар җыелышы: “Балаларны ничек һәм нәрсә белән шөгыльгә тартау?”<br>2.Ата-аналар почмагына консул-я: “Мәктәпкәчә яшьтәге баланың үз-үзен тотышындагы куркынычсызлык”<br>3.Әңгәмә: “Җәй көне үстерешле уеннар” |

### 2.4 Социаль дөнья белән таныштыру/Җәмгыять белән бәйләнеш

| № п/п | Оешмалар | Бурычлар һәл ителергә тиешле уртак эш | Балалар белән эш формалары |
|---|---|---|---|
| 1 | ДЮЦ №14, Огниво, Библиотека №8 | Бөтен яклап балаларны иҗади яктан үстерү | Бәйгеләр, күргәзмәләр, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | фестивальләр |
| 2 | Курчак театры ЯрЧаллы шәһәре «Әлинә»театры Әлмәт шәһәре | Балаларны театр культурасына тарту Театр белән танышу төзелешен әйтә белү: сәхнә, занавес, кулисы, тамаша залы, гримерная. | Театрга бару. Спектакльләр балалар бакчасында Әңгәмә театр хезмәткәрләре белән. |
| 3 | Балалар шифаханәсе №3 | Сәламәтләндерү буенча эш, консультацияләр өчен педагоглар һәм ата-аналар | Балаларны белгечләр карау, тәкъдимнәр. |

**3.Оештыру бүлеге 3.1.Төркемнең материаль-техник нигезе.**

Ноутбук, тавыш колонкалары.
Дидактик информацияләр: татарча мультфильнар, балалар өчен җырлар.

Кабул итү бүлмәсе: балалар киеме өчен шкафлар – 26 шт; балалар эшен күргәзмә почмагы – 1шт; балалар рәсемен куя торган магнит такта -1 шт; белдерүләр өчен магнит такта – 1 шт; эти – әниләргә информация өчен кесәле стендлар, скамейкалар – 4 шт;
Туалет бүлмәсе: унитаз - 3 шт; раковина –3шт; җыештыру кирәк – яраклары саклана торган шкаф – 1 шт; сөлгеләр элер өчен шкаф – 26 шт; сөлгеләр – балалар саны буенча, сабын савытлары – 3шт; ванна - 1шт.
Юу бүлмәсе: раковина – 2 шт; беренче аш өчен тәлинкәләр; икенче аш өчен тәлинкәләр; салат өчен тәлинкәләр; савыт-саба шкафы; чиләкләр; кастрюлләр; чайник; поднос; савыт-саба өчен киптергеч; чүмечләр; стаканнар; салфетницалар;
Йокы бүлмәсе: балалар кроваты -25 шт.; матраслар; мендәрләр; одеяллар; урын-җир комплекты; язу өстәле – 1 шт.; массаж келәме; чиста керләр шкафы һәм кием шкафы – 1 шт;
Төркем бүлмәсе: уенчыклар шкафы – 3 шт; уку шкафы – 1 шт; өстәлләр – 13 шт; урындыклар - 24 шт;

**3.2. Төркемнең программа-методик нигезе**

1. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы “Туганнан алып мәктәпкәчә”, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә, МОЗАИКА-СИНТЕЗ, Москва, 2015, ХӘТЕР, Казан, 2017
2. Р. К. Шаехова “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы” Казан, 2012.
3. Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма / Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ.- Казан: Фолиант, 2013.
4. Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге /Хәзрәтова Ф.В., Дорофеева Н.К., Закирова К.В., Гарафиева Г.З.- Казан, 2013.
5. Әй уйныйбыз, уйныйбыз... Методик кулланма/Закирова К.В., Мортазина Л.Р.-Казан, 2013.
6. Үстерешле уеннар Методик кулланма/Закирова К.В.. Кадыйрова Р.Ә.- Казан,2013.
7. Әхлак нигезе матур гадәт Методик кулланма/Закирова К.В., КадыйроваР.Ә,-Казан6Мәгариф, 2014.
8. Балачак аланы Балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләре өчен хрестоматия/Закирова К.В.,-Казан:РИЦ,2011.
9. Балалар бакчасы Әти-әниләр һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен уку китабы/Фәрит Йосыф, Гөлназ Йосыф, Фәридә Хәмид-Казан:Раннур, 2003.
10. Тәрбиядән яраладыр тәрбия-Яр Чаллы: Идел йорт, 2002.
11. Бала бишеге – гомер ишеге –Яр Чаллы: Идел йорт, 2000.
12. Бал бабай Балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен хрестоматия/Зарипова З.М., Хәмитов И.М.- Яр Чаллы, 2002.

13. Җиләк малай Р.Бәшәр-Яр Чаллы: Газета - китап нәшрияты, 2002.
14. Ал кирәк, гөл кирәк Балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен кулланма/Рәшит Ягъфәров.
15. Татар халык табышмаклары - яр Чаллы: Идел йорт, 2000.
16. Бармакларны уйнатабыз – сөйләм телен үстерәбез/Дәүләтшина Л.Х.-Казан, 2009.
17. Математикага өйрәнәбез/З.Г.Шәрәфетдинова, И.Җ.Хәбибуллина, Ф.В.Хәзрәтова – Казан:Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты, 2010
18. Сурәтләү һәм кору эшчәнлеге/Р.М.Зиннатова, Л.Ә.Гарәева, А.Г.Зворыкина-Казан: Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты, 2010
19. Табигатьнең сафлыгы – күңелеңнең пакълеге/Яр Чаллы шәһәре. "Идел-йорт" нәшрияты.2004
20. Табигатьтә кунакта/Ә.Х.Габдрахманова – Яр Чаллы. 2016

### 3.3. Эш төрләре буенча үстерелешле мөһит булдыру. Үсеш үзәкләре.

| **Үсеш үзәкләре** | **Җиһазлар** |
|---|---|
| Хәрәкәтчәнлек үзәге | Массаж ясау өчен келәм, обруч, кегли, туплар, төсле шарлар, мишень,х/у маскалар, сикергечләр, ыргытып кертү өчен түгәрәкләр, төрле тасмалар. |
| Сюжетлы уен үзәге | Уен җиһазлары: карават, шкаф, кухня шкафы, өстәл, урындыклар; с/р уеннар "Гаилә","Шифахаһәнә", "Төзелеш", "Сату үзәге", "Мода йорты", "Матурлык үзәге") уеннарга атрибутлар:курчаклар, кухня һәм чәй өчен савыт-саба; азык-төлек,яшелчә, җиләк-җимеш муляжлары; курчаклар өчен урын-җир япмалары; үтүкләр, үтүкләү тактасы; сумкалар, кәрзиннәр, чәчтараш өчен кирәк-яраклар; шифаханә өчен кирәк-яраклар; йөк машиналары, җиңел машиналар, йорт һәм кыргый хайваннарның сыннары. |
| Конструкцияләү үзәге | Төрле шакмаклар, легалар, конуслар, өчпочмаклар.Агач конструктор, "Шәһәр конструкторы", "Агач өй конструкторы" |
| Экспериментлар үзәге | Су, ком савытлары, алъяпкычлар, лейкалар, кечкенә көрәкләр, тырмалар, төрле кечкенә ташлар, әкәм-төкәм кабыклары |
| Театр һәм җыр үзәге | Театр эшчәнлеге почмагы "Әкиятне танып әйт" д/у, өстәл театры, бармак театры, уенчыклар театры, ширма<br>Музыкаль эшчәнлек почмагы музыкаль инструментлар: быргы, барабан, гармун, кашыклар, шылтырамалар.<br>Күргәзмә материаллар, дидактик уеннар. |
| Сәнгать үзәге | Такталар, пластилин, тозлы камыр, табигый материаллар. - тасвирлау эшчәнлеге өчен почмак, кәгазьләр, карандашлар, балчык, мөһерләр,калыплар,буяулар,гуашь,балавыз акбурлары, кайчылар, пумалалар, бизәү үрнәкләре, тозлы камыр,яраксыз материаллар,сәнгать жанрларының үрнәкләре рәсемнәре h.б.; |

| | |
|---|---|
| Китап үзәге | Китап почмагы (яшь үзенчәлекләренә яракланган китаплар, әкиятләргә иллюстрацияләр, пазл уеннары. “Әкиятне җый”, “Әкиятне танып әйт” уены, язучылар портретлары - Г.Тукай) |
| Тоемлау үзәге | Кул-бармак эшчәнлегепочмагы (шнуровка, массаж туплары, «Бармаклар». Дидактик уеннар: “Зур-кечкенә”, “Өлешләрен тап”, “Рәсемне җый”, “һөнәрләр дөньясы”, “Кыргый хайваннар”, “Җиләк-җимеш”, “Яшелчәләр”; “Панно”, “Табигать күренеше”; “Серле капчык” |

**3.4. РЕЖИМ ДНЯ ДЛЯ ВТОРОЙ МЛАДШЕЙ ГРУППЫ №3**
**№3 ИКЕНЧЕ КЕЧКЕНӘЛӘР ТӨРКЕМЕ ӨЧЕН КӨНДӘЛЕК РЕЖИМ**

| | | |
|---|---|---|
| 06.00 – 06.30 | Балаларны төркем бүлмәсендә кабул итү. Уеннар, балаларның тәрбияче белән бергә эшчәнлеге | |
| 06.30 – 07.40 | Саф һавада йөрү, балаларны урамда кабул итү | |
| 07.40 – 07.48 | Иртәнге гимнастика | |
| 07.48 – 08.10 | Гигиеник процедуралар, иртәнге ашка әзерлек | |
| 08.10 – 08.30 | Иртәнге аш | |
| 08.30 – 09.00 | Гигиеник процедуралар, реж. вакытында туган телне ныгыту, констр. эшчәнлек | |
| **Дүшәмбе** | 08.50-09.05 | Музыка белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.05-09.25 | Төркем бүлмәсен җилләтү |
| | 09.25-09.40 | Әвәләү/кисеп ябыштыру белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.40-09.50 | Икенче иртәнге аш |
| | 09.50-10.00 | Саф һавада йөрергә әзерләнү |
| | 10.00-11.30 | Саф һавада йөрү (күзәт-р, хезмәт, уеннар, бал-ң тәрб б-н һәм мөст эшч). |

| | | |
|---|---|---|
| **Сишәмбе** | 09.00-09.15 | ФЭМП белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.15-09.30 | Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге, төркем бүлмәсен җилләтү |
| | 09.30-09.40 | Икенче иртәнге аш |
| | 09.40-09.50 | Саф һавада йөрергә әзерләнү |
| | 09.50-11.30 | Саф һавада йөрү (күзәт-р, хезмәт, уеннар, бал-ң тәрб б-н һәм мөст эшч) |
| | 10.55-11.10 | Физик культура белем бирү эшчәнлеге саф һавада |
| **Чәршәмбе** | 08.50-09.05 | Физик культура белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.05-09.15 | Төркем бүлмәсен җилләтү |
| | 09.15-09.30 | Сөйләм теле белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.30-09.40 | Икенче иртәнге аш |
| | 09.40-09.50 | Саф һавада йөрергә әзерләнү |
| | 09.50-11.30 | Саф һавада йөрү (күзәт-р, хезмәт, уеннар, бал-ң тәрб б-н һәм мөст эшч). |
| **Пәнҗешәмбе** | 09.00-09.15 | Музыка белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.15-09.25 | Төркем бүлмәсен җилләтү |
| | 09.25-09.40 | Рәсем белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.40-09.50 | Икенче иртәнге аш |
| | 09.50-10.00 | Саф һавада йөрергә әзерләнү |
| | 10.00-11.30 | Саф һавада йөрү (күзәт-р, хезмәт, уеннар, бал-ң тәрб б-н һәм мөст эшч). |
| **Җомга** | 09.00-09.15 | Физик культура белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.15-09.25 | Балаларның мөстәкыйль эшчәнлеге, төркем бүлмәсен җилләтү |
| | 09.25-09.40 | Әйләнә-тирә дөнья белән танышу белем бирү эшчәнлеге |
| | 09.40-09.50 | Икенче иртәнге аш |
| | 09.50-10.00 | Саф һавада йөрергә әзерләнү |
| | 10.00-11.30 | Саф һавада йөрү (күзәт-р, хезмәт, уеннар, бал-ң тәрб б-н һәм мөст эшч) |
| 11.30 – 11.40 | Саф һавадан керү, гигиеник процедуралар | |
| 11.40-12.10 | Көндезге аш | |
| 12.10 – 12.15 | Гигиеник процедуралар, көндезге йокыга әзерлек | |
| 12.15-15.15 | Көндезге йокы | |
| 15.15 - 15.20 | Йокыдан тору, сәламәтлекне ныгыту чаралары, һава-су процедуралары | |
| 15.20 – 15.30 | Төшке аш | |
| 15.30 – 16.00 | Шәхси эш, нәфис әдәбият уку, бал-ң тәрбияче белән яисә мөст-ь. эшч, уен эшч | |
| 16.00 - 16.10 | Гигиен.процед., кичке ашка әзерлек | |
| 16.10 - 16.30 | Кичке аш | |
| 16.30 – 17.00 | Гигиен.процед., урамда йөрергә әзерлек | |
| 17.00 - 18.00 | Саф һавада йөрү, уеннар, әти-әниләр белән эш, балаларны өйләренә озату | |
| Время начало занятий может меняться в соответствии с сеткой максимальной нагрузки. | | |

## 3.5. Турыдан- туры белем бирү эшчәнлегенең расписаниесе

| | | |
|---|---|---|
| **Дүшәмбе** | 08.50-09.05<br>09.25-09.40 | Музыка белем бирү эшчәнлеге<br>Әвәләү/кисеп ябыштыру белем бирү эшчәнлеге |
| **Сишәмбе** | 09.00-09.15<br>10.55-11.10 | ФЭМП белем бирү эшчәнлеге<br>Физик культура белем бирү эшчәнлеге саф һавада |

| | | |
|---|---|---|
| **Чәршәмбе** | 08.50-09.05<br>09.15-09.30 | Физик культура белем бирү эшчәнлеге<br>Сөйләм теле белем бирү эшчәнлеге |
| **Пәнҗешәмбе** | 09.00-09.15<br>09.25-09.40 | Музыка белем бирү эшчәнлеге<br>Рәсем белем бирү эшчәнлеге |
| **Җомга** | 09.00-09.15<br>09.25-09.40 | Физик культура белем бирү эшчәнлеге<br>Әйләнә-тирә дөнья белән танышу белем бирү эшчәнлеге |

**Искәрмә:**

Режим моментларында – ана теле, конструкцияләү.

## 3.6. Сәламәтлекне саклау чаралары

Сәламәтлек белем бирү эшчәнлеге эчтәлеге балаларның сәламәтлеген саклау, аларда сәламәтлек культурасы нигезләрен формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлдерелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Балаларның физик һәм психик сәламәтлекләрен ныгыту буенча эшне; оешма төрен һәм тибын, булган шартларны, төркем тулылыгын, балаларның сәламәтлек һәм үсеш үзенчәлекләрен, шулай ук төбәктәге климатик һәм ел фасыллары үзенчәлекләрен исәпкә алып, бала организмын чыныктыру эшен дәвам итү.

Шәхси гигиена процесслары турындагы күзаллауларын баету. Гигиена нормалары һәм кагыйдәләрен аңлы һәм мөстәкыйль рәвештә үтәүләренә ирешү.

Гади һәм чиста киенү, киемнәрне тәртипләп төрү, бүлмәдә чиста аяк киемендә йөрү күнекмәләрен үстерү.

Ашаганчы һәм ашагач, пычрангач, туалеттан соң кулларын мөстәкыйль рәвештә юарга, тешләрен чистартырга, ашаганнан соң авызны чайкарга, йоклар алдыннан аякларны юарга гадәтләндерү.

Пөхтә ашау күнекмәләрен камилләштерү: ризыкны азлап кына алу, тавышсыз гына ашау, бик кайнар ризык ашамау, коймау, савыт-сабаны дөрес файдалану.

Милли ризыклар һәм эчемлекләр (умач, татарча азу, казам пылавы, кара җимеш һәм өрекле чәй, хуш исле чәй һ. б.) белән таныштыру.

Бала организмы өчен кирәк булган витаминнар турында күзаллау булдыру. Ризык кабул итү режимын үтәү, җиләк- җимеш, яшелчә, балык һәм сөт ризыкларын (кайнаган сөт, кефир, корт), ит һәм башка файдалы ашамлыкларны куллануга ихтыяҗ тәрбияләү.

«Сәламәтлек» һәм «авыру» төшенчәләре, халык медицинасының кайбер чаралары белән таныштыру. Бәрелгәндә, киселгәндә үз-үзеңә һәм башка балаларга элементар ярдәм күрсәтү, үз сәламәтлегең турында кайгырту күнекмәләре формалаштыру.

| **Айлар** | **Мероприятияләр** |
|---|---|
| АВГУСТ | Җиләк-җимешләр,соклар,кабул итү,психогимнастика “Веселая пчелка”, уеннарда йога, ”Кошечка”, тын алу күнегүләре “Җил исә”, ”Насос” йөрү һәм йөгерү корригируюший юллардан, урамда ялан аяк йөрү. |
| СЕНТЯБРЬ | Җиләк-җимешләр,соклар,кабул итү. Бармаклар өчен гимнастика “Кәбестә турыйбыз”. ”Сидит белка на тележке”, тын алу гимнастикасы “Җил исә”, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү. |
| ОКТЯБРЬ | Җиләк-җимешләр, соклар, витаминнар кабул итү, тавыш гимнастикасы “Елаклар утравы”, уеннарда йога, “Песи сөт эчә” йокыдан тору өчен урын-җирдә күнегүләр ясау, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү. |
| НОЯБРЬ | Җиләк-җимешләр, соклар,витаминнар кабул итү. Бармаклар өчен уеннар “Апельсин”, “Тиен” тын алу өчен күнегү “Салкын-кызу”, кечкенәләр өчен йога “Маленьких волшебников”, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү. |
| ДЕКАБРЬ | Борынга оксалин мазы сөртү, витаминнар кабул итү, тын алу гимнастикасы “Метелица”, бармак уеннары “Прятки”, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү. |
| ЯНВАРЬ | Борынга оксалин мазы сөртү, тын алу гимнастикасы “Холодно- жарко”, бармак уеннары “Минем гаиләм”, урын-җирдә өстендә күнегүләр үтәү, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү. |
| ФЕВРАЛЬ | Борынга оксалин мазы сөртү, җиләк-җимешләр, соклар, витаминнар кабул итү, тын алу гимнастикасы “Морозко”, кечкенәләр өчен йога куллану “Маленьких волшебников”, урын-җирдә өстендә күнегүләр үтәү, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү. |

| | |
|---|---|
| МАРТ | Җиләк-җимешләр, соклар, витаминнар кабул итү, тын алу гимнастикасы “Гудит самолет”, бармак уеннары “Кәбестә турыйбыз”, ”Белочка”, урын-җирдә өстендә күнегүләр үтәү, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү |
| АПРЕЛЬ | Җиләк-җимешләр, соклар, витаминнар кабул итү, тын алу гимнастикасы “Ракета взлетает” күркәләр белән бармаклар өчен күнегүләр, йога “Маленьких вошебников” уяну өчен күнегүләр ясау, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү |
| МАЙ | Җиләк-җимешләр, соклар, витаминнар кабул итү, бармаклар өчен уеннар “Прятки”, “Минем гаиләм”.”Цветочки”, тын алу өчен күнегүләр с мыльными пузырями, уяну өчен күнегүләр ясау, корригируюший юллардан йөрү һәм йөгерү. |

### 3.7 Традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар

Күңел ачу чаралары, бәйрәмнәр - һәр балага төркем бүлмәсендә, урамда ирекле уеннар уйнарга, парк, шәһәр урамы буйлап сәяхәт кылырга, актив һәм пассив ял итәргә мөмкинлек, эмоциональ тынычлык бирә, баланың үзенә шөгыль таба белү сәләтен формалаштыра.

| Ай | Музыкаль Бәйрәмнәр | Спорт бәйрәмнәре | Фольклор бәйрәмнәр, вакыйгалар | Традицияләр |
|---|---|---|---|---|
| Сентябрь | 1 сентябрь – Белем көне (музыка җитәкчесе) | Кем тизрәк? (тәрбиячеләр, ФК инструкторы) | Көз бәйрәмнәре (тәрбиячеләр) | 27 сентябрь – тәрбиячеләр көне (балалар бакчасында эшләүчеләрнекотлау) |
| Октябрь | Музыка көне (музыка җитәкчесе, ФК инструкторы | | | Өлкәннәр көне |
| Ноябрь | Игелеклелек көне. | «Сәламәтлек көне» (ФК инструкторы) | | 4 ноябрь –Халыклар бердәмлеге көне. 24 ноябрь – Аналар көне (тәрбиячеләр) |
| Декабрь | Яңа ел (музыка | | Мастер-класс «Үз кулың белән курчак | Конкурс” Яңа ел уенчыгы” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | җитәкчесе) | | тегү»<br><br>(тәрбиячеләр) | |
| Январь | Чыршы белән саубуллашу, уенчыклар күргәзмәсе | Кышкы уеннар<br><br>(тәрбичеләр, ФК инструкторы) | | Экологик акция «Кошларны ашат»<br><br>(тәрбиячеләр) |
| Февраль | | 23 февраль –<br><br>Минем әти иң - иңе.<br><br>(ФК инструкторы) | | |
| Март | 8 Марта<br><br>(музыка җитәкчесе) | Мы растем сильными и здоровыми<br><br>(тәрбичеләр, ФК инструкторы) | Широкая Масленица, (тәрбиячеләр) | Навруз<br><br>День театра<br><br>(тәрбиячеләр) |
| Апрель | День птиц<br><br>(тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе) | День космонавтики<br><br>(тәрбичеләр, ФК инструкторы) | "Во саду ли, в огороде"<br><br>(тәрбиячеләр) | День Земли<br><br>День рождения Г.Тукая<br><br>(тәрбиячеләр) |
| Май | День Музыки<br><br>(тәрбиячеләр, музыка җитәкчесе) | День семьи<br><br>(тәрбичеләр, ФК инструкторы) | Праздник воздушных шаров<br><br>(тәрбиячеләр) | День Победы<br><br>День рождения А.С.Пушкина<br><br>(тәрбиячеләр) |

**Кулланылган әдәбият исемлеге:**


1. Мәктәпкәчә төп белем бирү программасы “Туганнан алып мәктәпкәчә”, Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә, МОЗАИКА-СИНТЕЗ, Москва, 2015, ХӘТЕР, Казан, 2016.
2. Р. К. Шаехова “Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы” Казан, 2012.
3. Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма / Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибулина И.Җ.- Казан: Фолиант, 2013.
4. Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге /Хәзрәтова Ф.В., Дорофеева Н.К., Закирова К.В., Гарафиева Г.З.- Казан, 2013.
5. “Гаиләдә һәм балалар бакчасында әхлак тәрбиясе” методик кулланма. Закирова К.В. Казан: Мәгариф, 1999-224 б.
6. “Гөлбакча” балалар бакчалары өчен хрестоматия. 1990.
7. “Уйный-уйный үсәбез” Закирова К.В. Казан: Мәгариф, 2005-175б.

8. “Балачак - уйнап- көлеп үсәр чак” Закирова К.В.,Мортазина Л.В. Казан, 2012-192б.
9. “Балачак аланы” хрестоматия, Казан: РИЦ 2011-560б.

**3 нче икенче кечкенәләр төркеменең эш программасына кыскача презентация.**

Программа 3-4 яшьлек балаларның, түбәндәге юнәлешләр буенча, төрле яклап үсешен тәэмин итә: социаль-коммуникатив, танып белү, сөйләм теле, нәфасәти һәм физик үсеш.

Программа ФДББСның максатчан юнәлешләренә ирешүне тәэмин итә.

Программа РФ законнары, РФ һәм ТР мәгариф министрлыгы норматив документларына нигезләнеп төзелде.

Балалар белән белем бирү эшчәнлеге балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән эшчәнлекләр белән алып барыла. Бу уен, аралшу, тикшеренү, тәҗрибә, эксперимент, матур әдәбият уку, кору, нәфасәти һәм хәрәкәт эшчәнлеге.

Программа татар телен тулысынча өйрәнүне күздә тота. Ф.В. Хәзрәтованың “Туган телдә сөйләшәбез” методик кулланмасы буенча алып барыла.

Ата-аналар белән эш түбәндәге юнәлештә алып барыла:

1. Балаларның сәламәтлеген саклау.
2. Бердәм белем бирү тирәлеген булдыру.
3. Балаларның хокукларын яклауны тәэмин итү.
4. Үсүче кешенең шәхесен формалаштыру.

Программаның бурычы: баланың үсешендә һәм аны тәрбияләүдә ата-аналарны союзниклар итеп ясау. Белем һәм тәрбия бирүдә, сәламәтлекләрен саклауда психологик һәм педагогик яктан ярдәм итү.

Ата-аналарның бу өлкәдә теләкләре мөмкин кадәр исәпкә алына. Шулай итеп, балалар бакчасы һәм гаилә арасында баланың уңай үсеше өчен юнәлдерелгән дустанә партнёрлык

**Кушымта 1**
**“Иҗтимагый-коммуникатив үсеш” белем бирү өлкәсе**
**Сюжетлы – рольле уеннарның комплекслы- тематик планы**

| Ай | Атна | Эшчәнлек темасы | Эшчәнлек эчтәлеге | Бурычлар |
|---|---|---|---|---|
| сентябрь | I | “Гаилә” | Әни кызын ашата, йокларга яткыра. Д./уен «Курчакны сыйлыйк», «Курчакны йокларга яткырыйк» | Рольләрне бүлешеп уйнарга өйрәнү, һөнәрләр һәм һөнәрләрнең эш кораллары турында белемнәрен үстерү, уйнаганда диалог |
| | | “Мин сатучы” | Әни кызы белән кибеткә килә, азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә үлчи. | |
| | II | “Парковка” | Юлда машиналар йөри, юл йөрү кагыйдәләрен үтеп машиналарны урыннарга куялар. | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | “Коткару хезмәте” | Коткару хезмәте кешеләре авыр очракларда ярдәмгә ашыгалар: пожар, юлларда хәләкәт. | коруны, татарча сөйләшүне булдыру. |
| | III | «Яшелчәләр кибете» | Әни кызы белән кибеткә килә, азык-төлек ала. Сатучы товар сата, үлчәүдә яшелчә үлчи.Д/уен “Яшелчә кибетендә ниләр сатыла”. | |
| | | «Көзге ярминкә» | Көзге ярминкәгә киләләр, яшелчә, җиләк-җимеш сатып алалар, хакларын очсызлаталар. | |
